ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4; Ватаным Татарстан, 2016, 9 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 пунктында “муниципаль хезмәт вазыйфаларына һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына” сүзләрен “муниципаль хезмәт вазыйфаларын һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен” сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяда:
а) 1 һәм 2 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләренә, шулай ук, яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) тиешле карары булган очракта, белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.
2. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен үрнәк квалификация таләпләре нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап, аның вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.”;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге үрнәк квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу – вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен; югары белем яисә урта һөнәри белем булу – вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча – кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә биш ел эш стажы булу;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфалары буенча – кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы булу;

муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары буенча – кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы булу.”;

в) 4 пунктта “белгечлек” сүзеннән соң “, әзерлек юнәлеше” сүзләрен өстәргә;

3) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

“$9^1$) әлеге Законның $18^1$ статьясында каралган белешмәләрне тапшырмаса;”;

4) 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле $18^1$ статья өстәргә:

“$18^1$ статья. **“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында белешмәләр тапшыру**

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачы граждан, муниципаль хезмәткәр һәркем файдалана алырлык мәгълүматны, шулай ук аларны таныырга мөмкинлек бирүче белешмәләрне урнаштырган “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтларның һәм (яисә) сайтлар сәхифәләренең адреслары турында белешмәләрне яллаучы вәкиленә түбәндәгеләр тапшыра:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачы граждан – хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәткә керү елына кадәрге өч календарь ел өчен;

2) муниципаль хезмәткәр – ел саен күрсәтелгән мәгълүматны тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен, моңа һәркем файдалана алырлык мәгълүматны муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында урнаштыру очраклары керми.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачы гражданнар тарафыннан – муниципаль хезмәткә кергәндә, ә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән рәвеш буенча тапшырыла.

3. Яллаучы вәкиленең карары буенча ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачылар һәм

муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган һәркем файдалана алырлык мәгълүматны эшкәртүне, шулай ук әлеге статьяның 1 өлешендә каралган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүне гамәлгә ашыралар.”;

5) 19 статьяда:

а) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:

“$10^1$) әлеге Законның $18^1$ статьясында каралган белешмәләрне;”;

б) 7 өлештә “Федераль закон” сүзләре алдыннан “2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы” сүзләрен өстәргә;

6) 22 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре, шулай ук яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасын биләү өчен белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителүе турындагы карары булган очракта, белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре;”;

7) 42 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

“5. Муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасының вазыйфаи бурычларына “Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында” 2015 елның 5 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу кергән очракта, 2019 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль хокукый актларда муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм (яисә) кече төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре куелмый (урта гомуми белем булган очракта) дип каралырга мөмкин.”;

8) Муниципаль хезмәткәрләргә аттестация үткәрү турында үрнәк нигезләмәгә кушымтаның 3 пунктында “белгечлеге” сүзеннән соң “, әзерлек юнәлеше” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 29 сентябре
№ 72-ТРЗ